РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Евлаштау, ул.Ш. Бариева, 23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Явлаштау авылы, Ш. Бариев урамы, 23 нче йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
09.11.2020

КАРАР
№ 10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Явлаштау авыл җирлеге Советының 2018 нче елның
28 нче апрелендә кабул ителгән 8 нче номерлы
«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Явлаштау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының
депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына һәм
муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары
турында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 8 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында " гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 11 498 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның гамәлен 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2020 елның 1 октябреннән, әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Авыл җирлеге башлыгы — Р.Х.Нуриев

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының 2020 елның 9 ноябре, № 10 карарына

Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының акчалата бүләкләре күләме

| Вазыйфалар исемнәре акчалата бүләк күләме (сумнарда) | акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 15759 |
| Депутатлар | 11498 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 11498 |